Бүгенге санда:




“Халык контроле” дәүләти системасында яңа категорияләр булдырылды. 2 бит.


# Дуслык
## Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Җомга **16** гыйнвар 2015 ел

№ 2 (10531)


**17 гыйнварга һава торышы:** аязучан болытлы һава; кар; җил көньяктан, 3 м/с; температура көндез -5°C, төнлә -5°C

## *Абзац-информ*

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

### РАЙОН ЯШЕЛЛЕККӘ КҮМЕЛӘЧӘК

Агымдагы елда районда 18600 төп яшь үсенте утыртылачак, аларның 5600е–шәһәрдә. Бу хакта табигатьне саклау буенча инспектор Рөстәм Ногманов хәбәр итте.

### ЭШМӘКӘРЛЕК ҮСӘ, ЭШСЕЗЛЕК КИМИ

2014 елда районда 356 икътисадый актив кече һәм микропредприятие, 1048 шәхси эшмәкәр үз эшчәнлеген алып барган. Кече эшмәкәрлек субъектлары саны шул рәвешле 35 берәмлеккә арткан, әйләнеш узган ел белән чагыштырганда 6,3 процентка үскән.

Тагы бер шатлыклы сан–быел районда рәсми рәвештә эшсезләр саны 71 кешегә кимегән.

### ҺӘЙКӘЛЛӘР ЯҢАРТЫЛАЧАК

Районда Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан Бөек Ватан сугышы батырлары истәлегенә куелган һәйкәлләрне яңарту буенча сметалар төзелә башлады. Кама аръягы һәм Нурлат шәһәре тарихы төбәк музее һәм район башкарма комитетының төзелеш бүлеге хезмәткәрләре составындагы эшче төркем шул максаттан өченче көн инде авылларга чыгалар. Бүген алар Колбай Мораса, Көрнәле Әмзә, Мамык, Тәрнәс авылларында булачаклар.

## Хезмәтен хөрмәтләп

“Нурлатнефть” НГДУсы начальнигының гомуми мәсьәләләр, кадрлар һәм социаль үсеш буенча урынбасары **Ильяс Вазыйх улы ӘНДАРОВ** республиканың нефть сәнәгате үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык фидакарь хезмәте өчен ТР Президенты Указы белән **“Фидакарь хезмәт өчен” медале** белән бүләкләнде.

# Авылларда боз шомарак

**Кизләү мәктәбенең хоккей тартмачыгы быел районда иң беренчеләрдән булып өлгерде**




**Киләсе атнадан шәһәр мәктәпләре арасында хоккей буенча традицион “Алтын алка” турниры башлана.**

Бүгенге көндә шәһәрдә биш ачык хоккей тартмачыгы бар. Әмма аларның күпчелегендә шугалакларны тәртипкә китерү, билгеләр салу эшләре әле бу атнада гына башланды. Әзерлек ягыннан “Буровик” хоккей тартмачыгы гына мактана ала: биредә инде “Татнефть” Кубогына берничә матч уздырырга да өлгерделәр. Быел әлеге турнирда Нурлаттан бораулау эшләре предприятиесенең “Буровик” (тренеры Назыйф Абдуллин) һәм “Нурлатнефть” идарәсенең “Искра” командалары (Владимир Шугаев) катнаша. Шәһәрнең башка тартмачыкларына “Алтын алка” турниры җанлылык кертер дип ышанабыз. Әмма 8нче, 9нчы мәктәпләр һәм гимназия бу бәйгедән дә нәүмиз калачак: аларның хоккей тартмачыклары юк. Дөрес, территорияләрендә шугалаклар әмәлләп, тимераякта шуу мөмкинлеге булса да тудыралар алар үзләре.

Ә менә авыллардагы хоккей тартмачыкларында күптән җанлылык хөкем сөрә инде. Бигрәк тә Фома, Кизләү, Киекле, Чулпан, Яңа Әлмәт кебек авылларда бу эш әйбәт куелган. Мисал өчен, районда бу сезондагы иң беренче турнирны киекleләр уздырды. Ә Кизләү мәктәбенең хоккей тартмачыгына бүген укучылар гына түгел, авыл яшьләре, хәтта өлкән буын кешеләре дә килеп ял итә, ди Кизләү мәктәбе директоры урынбасары Гөлнар Билданова. Башка авылларның шугалаклары да буш тормый. Шуңа яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге дә язга таба авыл командалары арасында беренчелек уздырырга ниятләп тора.

**Илназ МӨБАРӘКШИН**

КӨН КАДАГЫНДА

# Әзер тору кирәк

-36дан +1гә кадәр – кышкы һава торышының температура радиусы шундый. Кичә генә кисәк җылытты, атна азагына исә -10 булыр, дип фаразлыйлар.

Ә бит астма, йөрәк-кан әйләнеше, хроник, кан басымы авырулы кешеләр мондый тирбәлешне аеруча авыр кичерә.

Табиблар да һава торышының кисәк үзгәреп торуы аркасында медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итүче метеосизгер кешеләрнең артуын билгеләп үтәләр.

- Бу көннәрдә кабул итә торган дару препаратларының дозировкасын арттырырга һәм стресслы хәлләрдә калырга тырышмаска кирәк, - дип киңәш бирә Нурлат хастаханәсе терапия бүлеге мөдире Роза Фәхриева. – Койкалар саны чикле булу сәбәпле, табиблар авыруларның өйләренә үзләре чыгалар.

Гадәти көннәрдә “ашыгыч ярдәм”гә 60–65ләп чакыру керә торган булса, һава торышы кинәт үзгәргәндә аларның саны 80–85кә кадәр җитә. Бәйрәм көннәрендә мөрәҗәгать итүчеләр аеруча күп булган. Болары да әлеге дә баягы шул йөрәк-кан тамырлары авыруларына чакырулар. Ә хәзер, һава торышы 0дән +1гә кадәр тирбәлгәндә, ашыгыч чакырулар күбрәк астма авырулылардан керә. Табиблар мондый көннәрдә аларны үз сәламәтлекләренә игътибарлырак булырга, һава торышын күзәтеп барырга, дөрес тукланырга, сәламәт яшәү рәвеше алып барырга чакыралар.

Пенсионер Халидә Нигъмәтуллина температураның уйнавын һәрчак “үзе аша” үткәрә. Бу юлы да медицина хезмәткәрләре чакырмый булдыра алмаган. “Һава торышы үзгәрүгә үк сәламәтлегем белән проблемалар башлана. Кан басымы кисәк күтәрелә, дарулар гына булышмый. “Ашыгыч ярдәм”гә шалтыратам. Ярый әле, алар салкында да, буранда да тиз килеп җитә”, – ди ул.

“Ашыгыч ярдәм” службасында тәүлек әйләнәсе өч бригада эшли. “Әлбәттә, һава торышы начар булганда, транспорт белән барып җитү дә кыенлаша, әмма бер генә чакыру да игътибарсыз калмый”, – диде “ашыгыч ярдәм” службасының өлкән фельдшеры Наталья Әбделманова.

Кыш уртасына җитте. Әмма алда нинди буласын фаразлап булмый торган февраль дә бар әле. Димәк, сәламәтлекләре һава торышына бәйлеләргә үзгәрешләргә әзер торырга кирәк.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

АЛХӘБӘР

## Әйдәгез, искә алыйк!



Февральнең 8ендә Нурлат районын 20 елдан артык җитәкләгән легендар райком секретаре, Социалистик Хезмәт Герое, Бөек Ватан сугышы ветераны Габбас Кыям улы Гыйматдиновка 90 яшь тулган булыр иде. Әлеге дата уңаеннан газета махсус бит чыгарырга әзерләнә. Габбас Кыям улы белән бергә эшләгән ветераннар аның турында истәлекләре белән уртаклашырга теләсәләр, редакциягә килә яки 2-36-20, 2-36-13 телефоннары аша хәбәрләшә алалар.

*Хөрмәтле мөселман кардәшләр! 20 гыйнварда иртәнге 10да шәһәр Мәдәният сараена Мәүлид бәйрәменә рәхим итегез!*

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

“БЕРДӘМ РОССИЯ” ТОРМЫШЫ

## Ел җитди, бурычлар билгеле

**ЧӘРШӘМБЕ КӨННЕ “БЕРДӘМ РОССИЯ” БӨТЕНРОССИЯ СӘЯСИ ПАРТИЯСЕНЕҢ НУРЛАТ ҖИРЛЕ БҮЛЕКЧӘСЕ СӘЯСИ СОВЕТЫ УТЫРЫШЫНДА ЕЛГА БУРЫЧЛАР БИЛГЕЛӘНДЕ**


Автор фотосы

УТЫРЫШ КАТНАШУЧЫЛАР АЛДЫНА ЗУР БУРЫЧЛАР КУЙДЫ

2015нче ел Татарстан бердәмросслары өчен җитди һәм җаваплы ел булачак. Чөнки 13 сентябрьдә Татарстан Президентын һәм муниципаль сайлаулар көтелә. Һәм Нурлат җирле бүлекчәсенең быелгы беренче сәяси советы утырышында кабул ителгән эш планында көзге сайлау кампаниясен үткәрү белән бәйле эшләр дә зур урын алып тора. Алар арасында җирле сайлау штабы булдыру, инде традициягә кергән эчке партия тавыш бирүләре, “Бердәм Россия” көннәре оештыру һәм башка чаралар бар. Җирле бүлекчәнең башкарма комитеты җитәкчесе, сәяси совет әгъзасы Ралия Ханиева исә беренчел бурычлардан шулай ук фракцияләр эшчәнлеген көчәйтү, яшьләр белән һәм башлангыч бүлекчәләрдә эшне җанландыруны атады. Бүлекчә секретаре Равил Кузюров елның җитди буласын билгеләп, җирле дәрәҗәдә алып барыла торган төп эш курсларына тукталды.

- Нәрсә генә эшләсәк тә, аны нәтиҗәле итеп башкарырга тырышырга кирәк, - диде Равил Әфраимович һәм “Бердәм Россия”нең реаль эшләр партиясе булуына басым ясап:

– Узган елгы сайлау кампаниясе барышында үткәрелгән халык җыеннарында, “Бердәм Россия” көннәрендә күтәрелгән проблемаларның хәл ителүенә зур игътибар бирергә, халык ышанычын акларлык итеп эшләргә, - дигән бурыч куйды.

Сәяси совет утырышында шулай ук РФ Президенты Владимир Путинның Федераль җыенга еллык юлламасын тормышка ашыру буенча чаралар планы да каралды. Алар белән “Дружба” башлангыч бүлекчәсе секретаре Татьяна Фадеева таныштырды. Утырыш азагында бүлекчә секретаре Равил Кузюров Татьяна Зиновьевнаны узган елда башлангыч бүлекчәләр арасында үткәрелгән төбәк конкурсында уңышка ирешүе белән котлап, Рәхмәт хаты тапшырды.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

### ХӘБӘРЛӘР

#### КАДРЛАР СОСТАВЫ ЯҢАРТЫЛА

Яңа елны район кадрлар составында үзгәрешләр белән башлап җибәрде. Район башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары вазифасына Руслан Хәлил улы Морадыймов, “ТКХ ИК” МУПы директоры итеп Фәнис Минхәер улы Бакиров билгеләнде. Үзгәрешләр мәгариф учреждениеләренә дә кагылды. Шәһәрнең икенче гомумбелем бирү мәктәбе директоры вазифасы Елена Вячеславовна Матавинага йөкләнде.

**Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА**

#### ТАУ АРТЫНДА ТҮГЕЛ

Район хуҗалыкларында быелгы язгы чәчү кампаниясенә 323 трактор, 108ләп чәчкеч, 14 чәчү комплексы һәм башка туфрак эшкәртү техникасын җәлеп итү күздә тотыла. Язгы чәчүгә әзерлек буенча “Агромир” (элеккеге “Агро-Развитие”) хуҗалыгы өлгергәнлек күрсәтә, биредә барлык чәчү техникасының 70 процентлабы әзер. Шулай ук “Южная” һәм “ИРС”та да җанлылык сизелә, акрынлап башка хуҗалыклар да ремонт эшләрен башлап килә.

#### ДИН ГАЛИМНӘРЕ ЕЛЫ

2015 ел Татарстанда дин өлкәсендә “Татар дин галимнәре” елы дип игълан ителде. Шуның белән бәйле рәвештә республиканың барлык районнарында дин галимнәре тормышы, эшләре хакында материаллар җыю оештырылачак. Ел ахырында революциягә кадәр һәм совет чорында динебезгә, халкыбызга хезмәт иткән татар дин галимнәре турында альманах чыгару күздә тотыла.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

#### ӨЛКӘННӘР КОМПЬЮТЕРДА ЯРЫША

Пенсионерлар арасында “Өченче буын IT олимпиадасы”ның муниципаль турында 6 кеше үзен сынап карады. Аның нәтиҗәләре буенча Нурлат данын республика этабында Роза Абдуллина яклаячак. Ярышларның программасында теоретик сораулар, Интернет челтәрендә электрон почта белән эшләү, дәүләт порталыннан куллана белү кебек биремнәр бар иде.

#### БДИлар ҖИТӘ

Бердәм дәүләт имтиханнарын вакытыннан алда бирү этабы 17 февральдән старт алачак, төп этап 25 майдан башланачак.

– Агымдагы елда имтиханнарны үткәрү буенча Рособрнадзор махсус “кайнар линия” оештырды, – ди БДИ буенча район координаторы Неля Гыйззәтуллина. – +7 (843) 294-95-62 телефоны буенча укучылар һәм аларның әтиәниләре, укытучылар да имтиханны үткәрү процедуралары буенча үз сорауларын юллый ала.

**Зилия ӘКСАНОВА**

НӘТИҖӘЛӘР

## “Имин шәһәр” булырга охшаган

**Чәршәмбе, 14 гыйнвар көнне РФ МВДсының Нурлат районы буенча бүлегендә узган елга нәтиҗәләр ясалды һәм быелга бурычлар билгеләнде. Йомгаклау утырышында район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин, ТР МВДсы вәкиле Марсель Закиров, Нурлат шәһәре прокуроры Рамил Гарифуллин катнаштылар. Коллективның күрсәткечләре белән МВД бүлеге начальнигы Хафиз Нургатин таныштырды.**

Тулаем алганда, җинаятьләр саны кимегән. Әмма киң яңгырашлы җинаятьләр – үтерүләр, сәламәтлеккә белә торып зыян салу һәм моның үлемгә китерүе кебекләре арткан. Һәм мондый җинаятьләрдән 14 кешенең гомере өзелгән, бу – бик зур сан. Талау һөҗүмнәре дә 1дән 3кә, урлаулар 217дән 241гә җиткән.

– Тикшерелүче җинаятьләрнең артуы һәм туктатылырга өлгергән җинаятьләр санының кимүе аркасында җинаятьләрне ачу аз гына яхшырды. Ел нәтиҗәләре буенча җинаятьләр ачылуның гомуми проценты 61,5 процент булды. Әмма уңай динамикага да карамастан, фатирлардан, автотранспортлардан урлауларны ачу күрсәткече кимеде. Мондый җитешсезлекләргә бәйле рәвештә, бүлекнең оператив-служба һәм җитәкчеләр эшчәнлегенә 2013 елның 18 сентябреннән бер ел срокка махсус контроль кертелгән иде. Күрелгән чаралар нәтиҗәләре буенча быел бу контроль алынды, – дип билгеләп үтте Хафиз Шәрәфетдинович.

Аларның эшенә шулай ук Әсхәт Габдуллин һәм прокурор Рамил Гарифуллин да үз бәяләрен бирделәр.

Әсхәт Касыймович билгеләп үткәнчә, быел, ниһаять, “Имин шәһәр” видеосистемасын гамәлгә кертү планлаштырылган, бу җәмәгать тәртибен сизелерлек яхшыртырга тиеш. Рамил Таһирович тикшерү һәм сорау алуның сыйфатына аерым игътибар биреп, бүлек эшчәнлегенең проблемалы моментларына тукталды.

Азактан бер төркем полиция хезмәткәре ведомство бүләкләре белән билгеләп үтелде.

**Валентина ВАФИНА**

ИГЪТИБАР: ЯҢА КОНКУРС!

## Безнең ишегалдында...

**Нефтьчеләр урамындагы 8нче йорт ишегалдында күгәрченнәр өчен менә шундый оя ясап куйганнар.**



**“Дуслык” (“Дружба”, “Туслах”) район газетасы укучылары арасында яңа конкурс игълан итә. Ишегалдыгыз ни белән матур – барысына да шул хакта сөйли аласыз. Кар тутырдымы? Яки кызыклы балалар мәйданчыгы кордылармы? Кыскасы, фантазияләрегезне чикләмибез: һәм уңай, һәм тискәре мисалларны да кабул итәчәкбез.**

**Эшләрегезне К.Маркс ур., 19 адресына яки электрон почтага юллагыз (redak@list.ru). Тел.: 2-36-20, 2-36-13.**

“ХАЛЫК КОНТРОЛЕ”

## Мөрәҗәгатьләр кабул ителә

**Татарстанның “Халык контроле” дәүләт мәгълүмати системасына эшли башлаганнан бирле нурлатлылардан 401 заявка кергән. Аларның яртысыннан артыграгы – 223е узган ел булган.**

22 категория заявка арасында нурлатлылар икесеннән активрак файдалана. Аларның берсе территорияләрне төзекләндерүгә кагылышлы – узган ел бу уңайдан нурлатлылар мәгълүмат системасына 84 тапкыр мөрәҗәгать иткән. Тагы бер популяр төр – юл хәрәкәтен оештыру – анда 71 хәбәр бирелгән. Хәер, бу ике категория тулаем республика буенча да популяр икән. Аның беренчесенә татарстанлылар 9201, икенчесенә 6437 тапкыр мөрәҗәгать иткәннәр. Сишәмбе көнне Министрлар Кабинетында узган видеобрифингта шундый саннар китерелде. Әлеге һәм башка хәбәрләр арасында “Кире кагылды” статусы бирелгәннәре дә бар. Район башкарма комитетының эшләр идарәчесе Ралия Ханиева әйтүенчә, бу асылда кешеләрнең үз хәбәрләрендә сүгенү, тупас сүзләр файдалануы белән бәйле икән. Ялган мәгълүматлар да булгалый. Республика модераторлары һәр мөрәҗәгатьне эшкәртәләр, һәр факт тикшерелә һәм мәгълүмати системага хәл ителергә тиешле хәбәрләр генә кертелә.

Ә хәбәрләрнең ничек контрольдә тотылуын нурлатлылар үзләре дә сыный алды. Мисал өчен, җәен Нурлатта “Халык контроле” системасының баш модераторы Татарстанда кеше хокуклары буенча уполномоченный Сәрия Сабурская булып киткән иде. Ул нурлатлыларның зарларында күрсәтелгән адреслар буенча йөреп чыкты. Ә видеобрифингта ул бары тик бер генә хәбәр, анысы да нигезле рәвештә баш тартылган ике район арасында Нурлатны да уңай яктан билгеләп үтте. Монда “Халык контроле”нә мөрәҗәгать итәргә теләге булган һәркемнең дә заявкадан тыш, информсистеманы үстерү буенча үз тәкъдимнәрен калдыру мөмкинлеге бары да әйтелде. Ә быелдан “Халык контроле” системасына яңа – экстремизм, дини һәм милли нигездәге низаглар, коррупция фактлары, производстводагы җәрәхәтләр буенча категорияләр дә кертеләчәк. Моннан тыш, “Халык контроле”ның технологик платформасын гражданнар һәм дәүләт арасындагы хезмәттәшлекнең яңа механизмнарын эшләүдә файдалану ниятләнә.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

ҖИҢҮНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

# Озак яшәү сере

**Чулпан авылында яшәүче Мәрьям апа һәм Каим абый Сәмигуллинарның бергә гомер итүләренә 68 ел булган.**

Әле генә мәчеттән кайтып кергән ак сакаллы, җыйнак гәүдәле, җитез Каим бабайга 90 яшьне бирмәссең дә! Әтиләрен туган көне белән котларга җыелган балалары һәм оныклары янына район җитәкчелеге һәм авыл җирлеге Советы вәкилләре дә килеп кергәч, бабай тагын да ачылып китте. Үзенең 90 яшьлек гомер бәйрәме уңаеннан РФ Президенты Владимир Путин һәм район башлыгы Равил Кузюровның котлауларын кабул иткән Бөек Ватан сугышы ветераны, I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары иясе Каим ага озын һәм матур яшәүләренең сере тынычлыкта дип саный.

– Узган ел тормыш иптәшем 90 яшьлеген билгеләп үткән булса, быел миңа юбилейны күрергә насыйп булды, - ди сугыш ветераны тормышына шөкерана кылып. – 6 балам, 9 оныгым һәм 16 оныкам белән бергә тигезлектә яшәп гомер узганын сизми дә калынган. Гомер буе тормыштан канәгать булып, барлыкта яшәдек.

Төпчек улы Расыйх гаиләсе белән яшәүче Мәрьям апа белән Каим ага яшим дигән кешегә бар мөмкинлекләр дә җитәрлек бүген, дип саныйлар. Ә менә гаиләдә спортка мәхәббәт Каим агадан күчкән икән.

– Әти бу яктан барлык рекордларны уздырды, - ди улы Расыйх. – Гомер буе сәламәт яшәү рәвеше алып барды, мин инвалид дип беркайчан да төшенкелеккә бирелеп тормады, һәрвакыт хәрәкәттә булды.



Автор фотосы

СӘМИГУЛЛИННАР 68 ЕЛ ТАТУ ГОМЕР КИЧЕРӘ

Өч дистә ел гомерен Чулпан авыл советы секретаре һәм 9 елын хуҗалык бухгалтеры хезмәтенә багышлаган Каим агага тормышның төрле вакытларын күрергә насый булган. 1943нче елның гыйнварендa армиягә алынган егет маршал Рокоссовскийның Үзәк фронтына эләгә. Орлов-Курск дугасында, Брянск фронтында барган сугышларда йөзләгән километр араны җәяү узарга туры килә аңа. Һәм Брянск өчен барган сугышларның берсендә ул каты яраланып госпитальгә эләгә, аягын ампутацияләгәннән соң 1944 елда өенә кайта.

– Безнең җирлектә бүгенге көндә 1 сугыш ветераны һәм 6 сугыш ветераны толы яши, - ди Чулпан авыл җирлеге башлыгы Хафиз Ситдыйков. – Кызганыч, аяныч елларның тере шаһитлары елдан-ел кими бара шул.

– Безнең кебек өлкәннәргә мондый игътибар һәм кайгырту булганда яшәячәкбез әле, тарих та сакланыр, - ди бабай ил, республика һәм район җитәкчеләренә рәхмәт сүзләрен җиткереп.

КЕШЕ ҺӘМ ЗАКОН

# Үзең пешергән "ботка"...

Төшереп алырга яратучылар берәр стакан исерткеч эчемлек табу өчен нинди генә юлларга бармыйлар. Менә Нурлатта яшәүче М. да башта үзенең бар булган, аннан соң кәрәзле телефоны өчен ломбардтан алынган акчасын да эчеп бетерә. Аннан башка чараларга күчә – узып баручылардан бер шешә сыралык акча сорарга чыга. Яхшы кешеләр бар икән әле, булышалар. Узып баручы берәүдән, ә ул полиция хезмәткәре булып чыга һәм М. моны белә, сигарет сорап алгач, ул үз тикшерүен үткәрергә карар кыла. Дөресрәге, телевизор аша юкка гаепләнгән һәм тоткарланган кешеләр турында ишеткәннәрен чынлыкта тикшереп карарга ниятли. Моның өчен М. узып баручыдан якында гына бомжны күрмәдегезме дип сорый, ул минем паспорт, машина йөртү таныклыгы һәм 30 мең сум акча салынган барсеткамны урлады, дип тә өсти. Узып баручы үзенең полиция хезмәткәре булуын әйтеп, таныклыгын күрсәтә һәм полиция бүлегенә барырга тәкъдим итә. Әлбәттә, М.га белә торып ялган гариза биргән өчен җинаять җаваплылыгы каралган булуын да исенә төшерәләр, әмма М. бу хакта уйлап тормый һәм уйлап чыгарылган факт буенча гариза яза.

- Алдан тикшерү нәтиҗәсендә М. исеменә документлар, барсетка һәм акчалы янчыкның урланмаган булуы ачыклана, - ди Нурлат районы суды судья ярдәмчесе Альбина Сәмигуллина. – Гражданин М. паспорты үзендә булуын белеп торган, аның машина йөртү таныклыгы һәм 30 мең сум акчалы янчыгы һәм барсеткасы исә бөтенләй булмаган. Нәтиҗәдә, җинаять эше хокук саклау органнарын "тикшереп" карарга теләгән М.ның үзенә карата кузгатыла.

М.га карата җинаять эше судка җибәрелә, анда М.ны Россия Федерациясе Җинаятьләр кодексының белә торып ялган донос ясау маддәсе буенча гаепле дип табалар. Әлбәттә, М. гаебен таный, суд җинаятьнең иҗтимагый куркынычлылык дәрәҗәсен һәм характерын гына түгел, гаепләнүченең инвалидлыкка ия булуын һәм суд эскәмиясе артына беренче эләгүен исәпкә алып, штраф рәвешендәге җәза билгели.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**
(Нурлат районы суды материаллары буенча)

АВЫЛДАН-АВЫЛГА

### ЕЛНЫ – ИГЕЛЕКЛЕ ГАМӘЛДӘН

Иске Әлмәт авыл җирлегендә яңа ел игелекле гамәлләр белән башланып китте. Авыл җирлеге Советы депутаты Рәшит Билалов җирлектәге 50 балага яңа ел күчтәнәчләре җибәрде. Ә Түбән Кама шәһәрендә яшәүче авылдашлары Рәшит Гыйззәтов авылның 10 ятим баласына 500әр сум акчалата бүләк ясады.

### АВЫЛ ХИМАЯЧЕЛӘРДӘН УҢДЫ

Авылда узган Мәүлет бәйрәменә 50дән артык кеше җыелды. Чара мул табын артында Коръән сурәләре уку, вәгазьләр сөйләү һәм бүләкләр тапшыру белән үрелеп барган.

**Җәүдәт ХӘЙРУЛЛИН,**
Иске Әлмәт авылы

СОЦИАЛЬ КАЙГЫРТУ

# Гаризаларны яңабаштан теркәү башланды

**Чәршәмбедән Нурлатта балалар бакчасына ата-аналар түләве өлешен өстәмә компенсацияләүгә гаризаларны яңабаштан теркәү өчен документлар җыю буенча мобиль офислар эшли башлады.**

Бүгенге көндә Нурлат районында 1370 ата-ана өстәмә компенсация ала. Аларга уңай булсын һәм бу эш озакка сузылмасын өчен шәһәрнең 10 балалар бакчасында мобиль офисларның эш графигы төзелде. Республика матди ярдәм үзәгенең Нурлат районы буенча 33нче бүлеге белгечләре эш көне азагында билгеле бер вакытта мәктәпкәчә учреждениеләргә киләләр. Документлар гыйнвардан алып мартка кадәр өч агымда кабул ителәчәк.

– Компенсация ата-аналар барлык тиешле документларны тапшырган айдан алып исәпләнеләчәк. Алдагы түләүләрнең срогы чыгар алдыннан белгечләргә мөрәҗәгать итү ата-аналарның үзләре өчен мөһим, – ди 33нче бүлек мөдире Әлфия Сәрәева. – Инде өстәмә компенсация алучы ата-аналар бу процедураны яхшы белә һәм яңабаштан теркәлү өчен тиешле документларны алдан ук әзерләп куя. Моннан тыш, тәрбиячеләр дә аңлату эшләре алып баралар.

Компенсация алуга гаризаны Республика матди ярдәм үзәге бүлегенең үзендә дә бирергә була. Әмма әти яисә әни кеше нигезле сәбәпсез беркайда да эшләмәгән гаиләләргә компенсация түләнми.

**Маргарита ЛИТТА**

ФОТОФАКТ



Автор фотосы

## Чыршылар кирәксезгә калды

Нурлатлылар яңа ел бәйрәмнәренең төп атрибутларыннан арына башладылар – алар чүп контейнерларына куча башлады. Димәк, районның коммуналь службаларына эш артачак.

ФОТОФАКТ



Автор фотосы

## Җилне дә узып

Быел шәһәрдәге иң зур һәм озын тау шикәрчеләр бистәсе микрорайонында, ди халык. Ул балаларның гына түгел, аларның әти-әниләренең дә яраткан ял урынына әверелде.

**Маргарита ЛИТТА**

ФОТОФАКТ



Автор фотосы

## Куркыныч баш очында

Һава торышының кисәк җылытып җибәрүе аркасында йорт, биналар түбәләренә яткан калын кар катламының җәяүлеләр юлларына, парковкаланган транспорт өстенә шуып төшү ихтималы артты.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

# СПОРТ. КОТЛАУЛАР. БЕЛДЕРҮЛӘР

"НУРЛАТНЕФТЬ" НГДУсында

## Нефтьчеләр Кыш Бабай призларына көрәште



ВОЛЕЙБОЛДА I УРЫН АЛГАН ЦК ППН КОМАНДАСЫ

**Яңа ел каникулларында традиция буенча, "Нурлатнефть" НГДУсының М.Хуҗин исемендәге спорт комплексында идарә цехлары арасында Кыш Бабай призларына ярышлар узды. Анда 7 цех катнашты. Бу ярышлар өч көнгә сузылды.**

Спорт бәйрәмен тантаналы ачу вакытында идарәнең профком рәисе Ренат Мөхәммәтҗанов спортчыларны яңа ел бәйрәмнәре белән котлады һәм барысына да уңышлар теләде. Ярышлар исә волейбол турниры белән ачылды. Командалар бик матур һәм мавыктыргыч уеннар күрсәттеләр. Нәтиҗәдә, I урынны ЦК ППН алды. АУП белән 3нче ЦДНГ II-III урыннарны бүлештеләр.

Бүләкләү тантанасына исә "Татнефть" ААҖннән мәртәбәле кунаклар да килеп төште. Җәмгыятьнең профком рәисе урынбасарлары Александр Зимин һәм Эльвира Газизова – "Татнефть" ААҖнең "2014 елның иң яхшы Яңа ел чыршысы" конкурсының комиссия әгъзалары да әле. Алар НГДУның барлык объектларын карап чыктылар һәм бизәлешләрдәге иҗади карашка, оригинальлеккә яхшы бәя бирделәр.

Александр Зимин Нурлат спортчыларын җылы сәламләде, компания тормышында актив катнашулары өчен рәхмәтен җиткерде һәм барысына да яңа уңышлар, җиңүләр теләде.

Икенче көнне нефтьчеләр шашка, шахмат, бильярд кебек уеннарда ярыштылар. Бу бәйгеләрнең күптән инде үз фаворитлары да бар, алар елдан-ел призлы урыннар яулап торалар. Иң яхшы шашкачы булып янә Олег Васильев танылды, II урында пенсионер Виталий Сидоров, IIIдә – ЭХЗ монтеры Раил Мәслахов. Шахматта урыннар түбәндәгечә булды: Iдә – Михаил Безруков (3нче ЦДНГ), IIдә – Сергей Анисимов (Мехсервис), III дә – Вячеслав Членов (ЦК ППН). Бильярд уенында, узган елдагыча, Алексей Абрамовка тиңнәр булмады (ЦК ППН), Азат Кыямов (ЦК ППН) белән Азат Галиев (ЦТРС) II-III урыннарны бүлештеләр. Спартакиада өстәл теннисы ярышлары белән тәгәлләнде. Бу көнне җанатарларның яклау төркеме дә аерата актив булды. Шуңадырмы, һәр спортчы соңгы көчен биреп тырышты. Шул рәвешле, 35 яшькә кадәрге ир-атлар арасында I урынны янә яшь спортчы Андрей Королев яулады (ЦК ППН), II урында – Гомәр Ярмөхәммәтов (ЦК ППН), IIIдә – Илфат Мирзаҗанов (ЦК ППН). 35 яшьлек һәм аннан өлкәнрәк ир-атлар арасында иң остасы булып бу юлы да Николай Киргизов танылды (ЦК ППН). Денис Бахчеев (АУП) белән Михаил Безруков (ЦК ППН) II-III урыннарны алдылар. Хатын-кызлар арасында иң остасы Мария Лукьянова булды (АУП). Надежда Кириллова (ЦК ППН) һәм Любовь Трифонова (2нче ЦДНГ) II-III урыннарны бүлештеләр.

Ярышлар тәмамланганнан соң, барлык җиңүчеләргә дә Кыш Бабай призлары тапшырылды. 3нче ЦДНГ операторы, милли көрәш буенча 2013 һәм 2014 елларның көмеш призеры, татар-башкорт көрәше буенча төрле ярышларның күптапкырлар җиңүчесе Алмаз Мостафин да кыйммәтле бүләккә ия булды. Әлеге зур уңышлары өчен Алмаз Спорт остасы исеменә дә тәкъдим ителгән.

Кыш Бабай ярышлары тәгәлләнде, әмма "Нурлатнефть" спортчыларын яңа сынау көтә. Тиздән М. Хуҗин исемендәге спорт комплексында "Татнефть" ААҖнең XXVIII Спартакиадасы кысаларында өстәл теннисы ярышлары булачак.

**Марина КОРНИЛОВА**

*реклама хокукында*

## Котлыйбыз!

**Яңа Әмзә** авылында яшәүче кадерлеләребез **Фоат Вәлиулла улы һәм Тәскирә Габбас кызы Сәүҗиһановларны** гаилә корып яши башлауларына 55 ел тулу белән ихлас күңелебездән котлыйбыз.

Шушы көннән соң күпме юллар үттегез дә, күпме сулар кичтегез. Тормышны да бер мактадыгыз, бер сүктегез. Авырлыкларны сөйри-сөйри, бер якты көн килер дип, гел көттегез, өмет иттегез. Күпме сөенечләр кичердегез, күпме күңелсезлек, утлар йоттыгыз. Шул чакта да гаилә дигән парлы йортыгыз матур булды.

Авыр мизгелләрдә дә сез бер-берегезгә терәк, бер-берегезгә кирәк булып, кайгысын да, шатлыгын да, газабын да урталашып, җан җылысын тоеп, 55 ел бергә гомер кичердегез.

Сез булганга, әти-әни,
Нигезебез нурлы, сөйкемле,
Көнебезгә якты җылы бөркеп
Яныгыз сез йолдыз шикелле.
Яшәгез сез бергә озак-озак,
Ашыкмагыз әле сүнәргә,
Мөмкин булсын безгә - балаларга
Аз булса да бурыч түләргә.

**Балаларыгыз исеменнән кызларыгыз Гөлсирә, Кадрия, улыгыз Тәлгать, оныгыгыз Роза, киявегез Азат, оныкчыкларыгыз Азалия, Луиза.**

**Татарстан** поселогында туып, **Нурлатта** яшәүче безнең өчен кадерле әниебез, әбиебез **Асия Фатыйх кызы Нәфыйгована**ы 18 гыйнвардагы 70 яшьлек гомер бәйрәме – юбилее белән котлыйбыз. Аңа озын гомер, бәхет-шатлык, җан тынычлыгы телибез. Балаларыңның һәм оныкларыңның игелеген күреп, озак яшәргә насыйп итсен Ходай.

Яшәү шатлыгы син безнең өчен,
Яхшылыгың белән үрнәк син,
Авыр чакта сиңа таянабыз,
Безнең өчен һәрчак кирәк син.
Тыныч гомер бирсен Ходай
сиңа,
Сызламасын аяк-кулларың,
Бәхет-шатлык белән, кайгы
күрми
Үтсен синең алгы көннәрең.

**Иң изге теләкләр белән кызың Рузалия, улың Тәлгать, оныкларың Гүзәл, Лениза, Ильвина, оныкчыгың Данис.**

**Иске Әмзә** авылында яшәүче **Фәһимә Нәҗем кызы Гатинаны** олуг бәйрәме – 85 яшьлек юбилее белән котлыйбыз.

Сиңа ныклы сәламәтлек, күңел тынычлыгы, бәхетле тормыш телибез. Алдагы көннәрдә дә балаларың, оныкларың, оныкчыкларыңның кадер-хөрмәтен тоеп яшә. Һаман шулай ныклы йөрәкле булып кал.

Гомереңне безгә багышладың,
Кояш булып безне җылыттың,
Тыныч картлык бирсен сиңа
Ходай,
Бәрәкәтле булсын тормышың.

**Иң изге теләкләр белән барлык балаларың исеменнән улың Шамил, киленең Рәмзия.**

**Бикүле** авылында яшәүче кадерле тормыш иптәшем, сөекле әтиебез, яраткан зур әтиебез **Һади Фатыйх улы Шакиров** 17 гыйнварда 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Әтиебез! Кайгы-хәсрәт күрми, күңел тынычлыгы белән яшәргә язсын үзеңә. Тән сихәтлеге, иман байлыгы гомерлек юлдашың булсын. Ходай сине рәхмәтеннән ташламасын. Әни белән бергә игелекле, тыныч тормышта балаларыгыз, оныкларыгызның бәхетенә куанып яшәгез.

**Иң изге теләкләр белән тормыш иптәшең, кызың Алсу, улың Азат, киленең Ләйсән, оныкларың Адель, Аделя.**

**Киекле** авылында гомер итүче кадерле, газиз кызыбыз, апабыз **Миләүшә Илдус кызы Мөхетдинованың** гомер бәйрәме – юбилее!

Кадерлебез, синең бүген бәхет чәчәгең аткан мизгелләрнең бер чоры. Әйе, күр син, кара син янәшәңә, үзеңә, якыннарыңа – нинди матурлык, нинди хөрмәт, дәрәҗә хөкем сөрә. Болар барысы да – синең тырышлык, синең хөрмәт, холык, сабырлык, ягымлылык, мәрхәмәтлелек, ярдәмчеллек нәтиҗәсе.

Кайчан гына син әниебезнең кадерле кызы булсаң, бүген инде тормыш иптәшеңнең сөекле хатыны, ике күз нурың, кызларыңның изге әнисе, якыннарыңның хөрмәтле туганы, хезмәттәшләреңнең үрнәк өлгесе.

Сиңа киләчәгеңнең бүгенгедән дә матуррак, бүгенгедән дә бәхетлерәк булуын телибез. Бар хыялларың тормышка ашсын, тормыш иптәшеңнең янәшәсендә, балаларыңның иң кадерле әнисе булып, саулыкта, байлыкта озын гомер кичерергә язсын. Йөрәк түреңдәге бәхет очкыннары йөзеңдә елмаю булып һәрчак балкып торсын.

**Иң изге теләкләр белән, сине яратып әти-әниең, энең Алмаз, сеңлең Гөлназ гаиләләре.**


### КҮЧЕМСЕЗ МИЛЕК

*Бикүледә йорт. Т. 8-927-041-39-93.

*Йорт. Т. 8-900-32-56-027.

*Йорт. Т. 8-919-684-40-03.

*Йорт, 25 сутый участок, Ключи пос., алмаштыру мөмкин. Т.: 8-927-402-00-75, 8-927-466-11-91.

*Авылда ашамлыклар кибете. Т. 8-937-287-69-79.

*Биляр-Озерода йорт. Т.: 8-929-726-31-08, 8-927-425-10-16.

*Үзәктә («Россельхозбанк» каршында) 1 бүлмәле фатир, 1нче кат, офис өчен дә ярый. Т. 8-987-238-24-29.

*Үзәктә фатир, 30 кв.м, 1нче кат. Т. 8-927-031-23-45.

*Тыйматдинов ур.да 2 бүлмәле фатир. Т. 8-927-456-05-69.

*Ашыгыч, бүлмә, арзан. Т. 8-927-047-10-21.

*Йорт. Т. 8-937-77-40-132.

*Линейная ур.да гараж, документлары бар. Т. 8-937-526-98-82.

*Үзәктә 2 бүлмәле фатир. Яки алмаштырыла. Т. 8-927-036-78-76.

### АВТОТРАНСПОРТ

*«ДТ-75» өчен бульдозер-төягеч, 55000 сум. Т. 8-927-413-05-92.

*«КИА РИО», 8000 км. Т. 8-927-483-51-85.

*«КамАЗ», үзбушаткыч, 1991 елгы. Яки җиңел автомобильгә алмаштырыла. Т. 8-927-675-63-85.

*«ВАЗ-2110», 2003 елгы; «ВАЗ-2112», 2005 елгы; «Мерседес», 1996 елгы. Т. 8-937-529-47-48.

*«Шевроле Авео», 2010 елгы. Т. 8-927-455-44-98.

### БАШКАЛАР

*Бодай, арпа, солы, арыш, кукуруз. Китерәбез. Т. 8-927-470-08-25.

*Үгез бозаулар, китерәбез. Т. 8-927-870-49-62.

*Ком, ПГС, вак таш, елга ташы, керамзит; йөкләр ташу. Т. 8-927-440-31-55.

*Бильярд өстәле, бик яхшы, 3х1,5ле. Т. 8-937-621-37-80.

*Ысланган казлар, түшкәләр, эч-башлары. Т. 8-929-726-57-63.

*Бия, бозаулар Т. 8-927-037-36-06.

*Чәшке тун, 50/52ле. Т. 8-929-723-06-66.

*Утын. Т. 8-927-413-05-92.

*Какланган казлар һәм түшкәләр. Т.: 8-937-588-27-15, 8-960-033-23-77.

*8 айлык үгез бозау. Т. 8-927-245-32-03.

***Такталар (усак, нарат), борыслар. Киров урманыннан. Китерәбез. Т. 8-937-003-84-85.**

*Кулланылган "горка" стенка. Т.: 2-09-21, 8-927-045-59-30.

*Бала арбасы -трансформер: люлька, урамда йөри торган, машинага кәнәфи. Бәяләрен килешербез. Т. 8-937-004-95-48.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

***Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.**

***Йомшак җиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.**

*Йөкләр ташу, «ГАЗель», 4 м, 15 куб. Т. 8-927-247-12-61.

*Эвакуатор. Т. 8-927-450-33-50.

*Транспорт хезмәтләре күрсәтәбез: кран-манипуляторлы седельный тягач «КамАЗ», трал 40 тн; «МАЗ» седельный тягач, п/прицеп 20 тн. Т.: 2-56-66, 8-937-585-56-16.

